| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>31.05.2024 | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>1444 |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 3809 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы «Күп фатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күп фатирлы йортта уртак мөлкәт белән эш итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешсез сыйфатта һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артып киткән өзеклекләр белән хезмәт күрсәтү һәм эш башкару очрагында торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 491 нче номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу буенча карар, торак урынны карап тоту күләмен билгеләү , шулай ук мондый түләү күләменең чик үзгәреш индексларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертү буенча карар кабул итмәгән торак биналар хуҗалары өчен методик тәкъдимнәр раслау хакында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре торак фондының торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында » 2023 елның 30 ноябрендәге 3809 номерлы карарының 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«1.1. Әлеге түләү күләме күп фатирлы йортта уртак мөлкәтне файдаланганда һәм карап тотканда, социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йортларда күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм гомуми җыелышта түләү

күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән милекчеләр өчен кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне үз эченә алмый».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2024 елның 01 гыйнварыннан җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин